**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 4 сентябре** **№ 76**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 июнендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында”гы 40 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль законының 15 маддәсенә үзгәреш кертү турында”гы Федераль закон нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2017 елның 14 июнендәге 40 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган, “Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

Кагыйдәләрнең 85.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“85.8. туктап тору территориясенә инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Транспорт чараларының һәр туктау урынында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен 10 проценттан ким булмаган (әмма кимендә бер урын) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән урыннарны парковкалау өчен башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстн Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35нче йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Келәнче
авыл җирлеге Советы рәисе: Д.А. Кадыйров